ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.03.2020 № 118

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитетының 2017 елның 17 октябрендәге,
985 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен хезмәт күрсәтүләр, эшләр, товарларны сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 17 октябрендәге 985 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның 9 абзацын үз көчен югалткан дип таныргa;

6 пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә «Куелган товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килүе турында;»

6 пунктның 5 абзацында «каралган» сүзен «билгеләнгән тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2015 ел, 13 март, 233 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов